**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село
Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән
авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru;
http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2026 **Чирмешән авылы** №136

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 325 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 28.12.2024 ел, № 353-ФЗ, «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясындагы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2024 ел, № 538-ФЗ Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 325 номерлы карарына (18.10.2023 №292, 12.03.2025 №63 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5.2 пунктның 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәте әгъзалары реестры», әгәр җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү яисә җир кишәрлеген мондый ширкәткә түләүсез файдалануга бирү турында гариза бирелгән булса».

1.2. 2.8.3.2 пунктының 3 нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге бакчачылык яисә коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, моңа әлеге ширкәт әгъзасының (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен булса) яисә бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтендә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган, федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир кишәрлеген беренче чиратта яисә чираттан тыш бирүгә йә Җир кодексының 39_18 статьясы

нигезендә җир кишәрлеге бирүгә хокуклы (әгәр мондый җир кишәрлеге бакча кишәрлеге булса) граждан мондый гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклар керми, шулай ук гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып барган территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш (әгәр җир кишәрлеге гомуми билгеләнештәге җир кишәрлеге булып торса)».

1.3. 2.8.3.2 пунктының 13 пунктчасында «бастырып чыгарылды һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.4. 2.8.3.2 пунктының 16 пунктчасында «иң чик» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов